**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2024 елның «04» июленнән | № 180

Махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына аттракционнардан бушлай файдалануны билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле һәм керем китерә торган башка хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 40-325 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханәләр системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының үзәкләштерелгән китапханә системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенә түләүле чаралар оештырганда Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның балаларына «Карусель» аттракционыннан бушлай файдалануны билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда

http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов